| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Чукмарлинвского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Чукмарлы  авыл җирлеге<br>советы |

---

| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>30 декабрь 2025 ел | КАРАР<br>№ 14 |

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән гектарларда яисә баллогектарларда күрсәтелгән җир кишәрлегенә гади ялгыз вакланма рәвешендә өлешләрнең күләмнәрен билгеләү нәтиҗәләрен раслау турында

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 24.07.2002 ел, №101-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, РФ Хөкүмәтенең 16.09.2020 № 1475 белән «Гектарларда яки Балло-гектарларда күрсәтелгән җир өлешләренең күләмен гади дөрес вакланма рәвешендә билгеләү Кагыйдәләрен раслау турында» карарына таянып,  Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы белән, күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан 23.12.2025 елгы өземтә нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә, кадастр номеры 16:36:000000:187, мәйданы 6919283 кв. м булган Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, тер. Пай җирләре, 187 адресы буенча урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге гомуми өлешле җир кишәрлегенә гектарларда күрсәтелгән милек хокукында җирләрдән, өлешләр күләмен гади ялгыз вакланма рәвешендә билгеләү нәтиҗәләрен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

3. Әлеге карарны өч көн эчендә уставта билгеләнгән тәртиптә кушымтасыз рәсми рәвештә халыкка игълан итәргә.

Документның тулы тексты белән, «Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел, №152 Федераль Закон нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитетында танышырга мөмкин.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.